КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 7 май г.Казань № 424

Коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре территориясендә эчке инженерлык инфраструктурасы объектларын ремонтлауга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен аларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре территориясендә эчке инженерлык инфраструктурасы объектларын ремонтлауга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен аларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

3. Бу карар (Тәртипнең 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 2.2 пунктындагы өченче абзацыннан һәм 4.5 пунктыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин